# 2017/2018 уку йылында туган телләрне өйрәнү һәм туган телләрдә укытуның норматив-хокук нигезләре

Рәсәй Федерациясе Конституциясенең 68 нче статьясе (п.3) Рәсәй Федерациясендә “…аның барлык халыкларына туган телен саклау, аны өйрәнүгә һәм үстереүгә шарттар тудыру хокукы” гарантияли.

Башкортстан Республикасы Конституциясенең 54 нче статьясе “Башкортстан Республикасы үз территориясендә яшәгән халыкларга туган телләрен сакларға тиң хокуклар гарантияли, аны иректе өйрәнергә һәм үстерергә мөмкинлекләр тудыра”.

Рәсәй Федерациясенең 2012 нче елның 29 нчы декабреннән № 273-ФЗ “Рәсәй Федерациясендә мәгариф турында” Федераль Законының 14 статьясенә (п.1, 4) ярашлы һәркемгә мәгариф системаһы биргән мөмкинлекләрдән чыгып туган телендә белем алу хокукы гарантиялана.

“Рәсәй Федерациясендә мәгариф турында” Рәсәй Федерациясе Законының 9 нчы статьясенә (п.1-5) ярашлы Рәсәй Федерациясе гражданнары тәрбия һәм белем алу телен сайлау хокукына ия. Шушы ук законның 10 нчы статьясенә ярашлы туган телендә белем алырга теләүчеләргә дәүләт һәм мәгариф оешмалары барлык шартлар тудырырга бурычлы.

Башкортстан Республикасының 2013 нче елның 1 нче июленнән №696-З “Башкортстан Республикасында мәгариф турында”гы Законының 6 статьясенә (п.3) ярашлы Башкортстан Республикасында һәркем дәүләт аккредитация үткән мәгариф программалары нигезендә Федераль дәүләт белем бирү стандартларына ярашлы туган телендә белем алырга хокуклы. Моның өчен дәүләт шатлар тудырырга бурычлы.

“Башкортстан Республикасы халыклары телләре турында” Башкортстан Республикасы Законының 8 нчы статьясенә (п.1-5) ярашлы һәркем тәрбия һәм белем алу телен сайлау хокукына ия. 9 нчы статьясендә (п.1) дәүләтнең туган телләрне өйрәнү өчен шартлар тудыру бурычы билгеләнелә.

**Федераль исемлеккә кертелгән татар теле һәм әдәбияты фәне буенча уку-укыту коплектлары**

| № | Авторлар | Дәресле к исеме | Сыйныф | Боерыклар | Нәшрият | Басылган елы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| **Уку татар телендә алып барылган мәктәпләр өчен** | | | | | | |
| 1 | Харисова Ч.М., Максимов Н.В. | Татар теле | 5 | Приказ МОиН РФ от 21.04.16 № 459 | Татар. кит. нәшрияты | 2015 |
| 2 | Юсупов Ф.Ю., Харисова Ч.М. | Татар теле | 6 | | Татар. кит. нәшрияты | 2014 |
| 3 | Максимов Н.В., Набиуллина Г.А. | Татар теле | 7 | | Татар. кит. нәшрияты | 2014 |
| 4 | Закиев М.З. Максимов Н.В. | Татар теле | 8 | | Татар. кит. нәшрияты | 2015 |
| 5 | Закиев М.З Ибрагимов С.М.. | Татар теле | 9 | | Татар. кит. нәшрияты | 2015 |
| 6 | Ганиева Ф.А., Сабирова Л.Г. | Әдәбият | 5 | Приказ МОиН РФ от 21.04.16 № 459 | Татар. кит. нәшрияты | 2014 |
| 7 | Ганиева Ф.А., Гарифуллина М.Д. | Әдәбият | 6 | | Татар. кит. нәшрияты | 2014 |
| 8 | Абдуллина Д.М., Хисматова Л.К. | Әдәбият | 7 | | Татар. кит. нәшрияты | 2014 |
| 9 | Ганиева Ф.А., Рамазанова Ч.Р. | Әдәбият | 8 | | Татар. кит. нәшрияты | 2015 |
| 10 | Закирзянов А.М. Фахрутдинова Г.М | Әдәбият | 9 | | Татар. кит. нәшрияты | 2011 |
| **Уку рус телендә алып барылган мәктәпләр өчен** | | | | | | |
| **Рус телендә аралашучы укучылар өчен** | | | | | | |
| 1 | Хайдарова Р. З., Ахметзянова Г.М. | Татар теле | 5 | Приказ МОиН РФ от 8.06.2015 | Татармультфильм | 2014 |
| 2 | Хайдарова Р. З., | Татар | 6 | | Татармультфильм | 2014 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Назипова З.Р. | теле | | г. № 576 | | |
| 3 | Хайдарова Р. З., Малафеева Р.Л. | Татар теле | 7 | | Татармультфильм | 2014 |
| 4 | Хайдарова Р. З., Малафеева Р.Л. | Татар теле | 8 | | Татармультфильм | 2015 |
| 5 | Хайдарова Р. З. | Татар теле | 9 | | Татармультфильм | 2009 |
| 6 | Мотигуллина А.Р., Ханнанов Р.Г. | Әдәбият | 5 | Приказ МОиН РФ от 8.06.2015 г. № 576 | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2014 |
| 7 | Мотигуллина А.Р., Ханнанов Р.Г. | Әдәбият | 6 | | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2014 |
| 8 | Мотигуллина А.Р., Ханнанов Р.Г. | Әдәбият. | 7 | | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2014 |
| 9 | Мотигуллина А.Р., Ханнанов Р.Г., Валиуллина Р.Х. | Әдәбият | 8 | | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2015 |
| 10 | Мотигуллина А.Р., Ханнанов Р.Г. | Әдәбият | 9 | | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2015 |
| **Татар телендә аралашучы укучылар өчен** | | | | | | |
| 1 | Шамсутдинова Р.Р., Хадиева Г.К. | Татар теле | 5 | Приказ МОиН РФ от 8.06.2015 г. № 576 | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2015 |
| 2 | Сагдиева Р.К., Гарапшина Р.М. | Татар теле | 6 | | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2015 |
| 3 | Сагдиева Р.К., Харисова Г.Ф. | Татар теле | 7 | | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2015 |
| 4 | Сагдиева Р.К. Хайруллина Г.И. | Татар теле | 8 | | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2015 |
| 5 | Сагдиева Р.К. Кадирова Э.Х. | Татар теле | 9 | | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2015 |
| 6 | Хасанова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М. | Әдәбият | 5 | Приказ МОиН РФ от 8.06.2015 г. № 576 | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2014 |
| 7 | Хасанова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М. | Әдәбият | 6 | | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2014 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 8 | Хасанова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М. | Әдәбият | 7 | | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2014 |
| 9 | Хасанова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М. | Әдәбият | 8 | | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2015 |
| 10 | Хасанова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М. | Әдәбият | 9 | | «Мәгариф - Вакыт» нәшрияты | 2015 |

## Татар теленнән һәм әдәбиятыннан эш программаларын төзү үзенчәлекләре

Федераль дәүләт белем бирү стандартларына ярашлы уку предметлары, курслар, шул исәптән дәрестән тыш эшчәнлек буенча эш программалары төп гомуми белем бирүнең төп белем бирү программасын үзләштерүдә планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итәргә тиеш.

Уку предметлары, курслар, шул исәптән дәрестән тыш эшчәнлек буенча эш программалары төп гомуми белем бирүнең төп белем бирү программасын, аның структурасына кертелгән программаларны искә алып, үзләштерү нәтиҗәләренә куелган таләпләр нигезендә төзелә.

Дәрестән тыш эшчәнлек буенча эш программасы түбәндәге бүлекләрдән тора:

1) дәрестән тыш эшчәнлекнең көтелгән нәтиҗәләре;

2) дәрестән тыш эшчәнлекнең эчтәлеге (эшчәнлек формалары һәм төрләре күрсәтелеп);

3) тематик планлаштыру.

Уку предметлары буенча эш программалары түбәндәге структурага ия булырга тиеш:

1) программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр (шәхескә кагылышлы, метапредмет, уку фәненә кагылышлы нәтиҗәләр);

2) уку предметының, курсның эчтәлеге;

3) тематик план (һәр теманы үзләштерү өчен сәгать саны бирелеше белән).

Эш программасының максаты – билгеле бер уку-укыту предметы эчендә каралган белем бирү процессын планлаштыру, оештыру һәм идарә итү өчен уңай шартлар тудыру.

Эш программасының бурычлары:

– конкрет бер уку-укыту предметы кысаларында ФДББСын гамәлгә ашыру;

– укучыларның контингентын һәм белем бирү оешмаларының үзенчәлекләрен, максатын һәм бурычларын исәпкә алып, укупредметларының эчтәлеген, күләмен һәм тәртибен билгеләү;

Эш программасы түбәндәге фунцияләрне башкара:

– уку-укыту планында каралган төп вазифаларны үти;

– уку-укыту предметының белем бирү эчтәлеген билгели;

– уку-укыту предметы эчендә белем-бирү эчтәлегенең эзлеклелеген тәэмин итә;

– белем-бирү эчтәлегенә интегратив якын килү принцибын тормышка ашыра;

– җирле эчтәлекле модульне кертә;

– укыту-тәрбия бирү процессын оештыруга эзлекле, эшчәнлекле якын килү өчен шартлар тудыра;

– һәр укучының планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүен тәэмин итә.

## Эш программасын төзү алгоритмы

Эш программалары белем бирү учреждениеләренең компетенциясенә керә һәм мөстәкыйль рәвештә тормышка ашырыла.

Эш программалары билгеле бер белем алу дәрәҗәсен исәпкә алып төзелә.

Аерым бер уку-укыту предметының белем бирү эчтәлеге укытучының профессиональ осталыгы һәм үз дисциплинасын (предметын) ничек күзаллавыннан чыгып проектлаштырыла.

Эш программасы 2 экземплярда әзерләнә (берсе укытучының эшчәнлегендә кулланылса, икенчесе – белем бирү программасының бер структур элементы буларак рәсми кәгазьләр белән саклана).

Эш программасын төзегәндә, кабул иткәндә һәм раслаганда түбәндәге документларга игътибарлы булу сорала:

– ФДББС (ФГОС);

– уку-укыту предметының якынча (примерная) программасы;

– экспертизаны һәм апробацияне узган авторлык программасы;

– белем бирү учреждениесенең төп белем бирү программасы;

– УМК (дәреслек, дәреслеккә методик кулланма, эш дәфтәрләре, контроль-тикшерү материаллары, электрон кулланма).

Укытучының эш программасы административ структуралар тарафыннан укучыларның уку-укыту предметының эчтәлеге ни дәрәҗәдә үзләштерелгәнлеген өйрәнә һәм тикшерә торган документ булып тора.

Ул үрнәккә нигезләнеп, хаталарсыз, пөхтә итеп төзелә. Программаның тексты Word редакторы, Times New Roman шрифты, 12-14 кегль, юллар арасы (интервал) – 1, текст киңлегендә, һәрьяктан 1-2 см. кырлар калдырылып, А 4 бите форматында башкарыла. Титул бите документның беренче бите булып санала (ул биттә сан куелмый).

**Титул битендә:**

– белем бирү оешмасының тулы исеме;

– эш программасын кабул итү һәм раслау грифы;

– эш программасы төзелгән уку-укыту предметының исеме;

– сыйныф;

– эш программасын төзегән укытучының исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, квалификация категориясе;

– тору пункты (авыл, шәһәр, район һ.б.);

– эш программасы төзелгән ел күрсәтелә.

**Аңлатмалы язуда**:

– уку-укыту предметының гомуми белем бирүгә керткән өлеше;

– эш программасының үзенчәлекләре (УМК, төп идеяләре);

– уку-укыту предметының гомуми максатлары һәм бурычлары;

– укучылар белән оештырыла торган эш формалары һәм методлары;

– эш программасын тормышка ашыру вакыты чагылыш таба.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр** бүлегендә ФДББС таләпләренә ярашлы шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләр теркәлә.

“Туган тел” фәнен үзләштерүдә ирешелергә тиеш *шәхси* нәтиҗәләр булып түбәндәгеләр тора:

1) патриотик хис, илгә, Русиянең күпмилләтле халкының үткәненә һәм хәзергесенә хөрмәт тәрбияләү; үзеңнең этник чыгышыңны, үз халкыңның, туган җиреңнең тарихын, телен, әдәбиятын, мәдәниятен, кешелекнең һәм Русия халыкларының мәдәни мирас нигезләрен белү; күпмилләтле Русия җәмгыятенең гуманистик, демократик һәм традицион кыйммәтләрен үзләштерү;

2) укуга, хезмәткә карата җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру;

3) хәзерге дөньяның социаль, мәдәни, тел, рух күптөрлелеген исәпкә алган, фәннең һәм иҗтимагый тәҗрибәнең хәзерге заман үсеш дәрәҗәсенә тәңгәл килгән дөньяга тулаем караш формалаштыру;

4) башка кешегә, аның фикеренә, дөньяга карашына, мәдәниятенә, теленә, диненә, гражданлык позициясенә, дөнья һәм Русия халыкларының тарихына, мәдәниятенә, диненә, гореф-гадәтләренә, телләренә, кыйммәтләренә аңлы, ихтирамлы һәм игелекле мөнәсәбәт формалаштыру;

5) фәнне үзләштергәндә иҗтимагый тормышның формаларын һәм рольләрен, тәртиплелек кагыйдәләрен, яшәү нормаларын үзләштерү;

6) шәхси сайлап алу нигезендә әхлак проблемаларын хәл итүдә компетентлыкны һәм әхлакый аңлылыкны үстерү, үз гамәлләреңә карата аңлы һәм җаваплы мөнәсәбәт, әхлаклылык тойгысы һәм әхләкый яктан үз-үзеңне тәртипле тоту нормаларын формалаштыру;

7) фәннәрне үзләштерү барышында, фәнни-эзләнү, иҗади һәм башка эшчәнлек вакытында, шулай ук аралашу процессында (укучы-укучы, укучы-укытучы һ.б) коммуникатив компетентлыкны үстерү;

8) җәмгыять һәм кеше тормышында гаиләнең әһәмиятен аңлау, гаилә кыйммәтләрен кабул итү, гаилә әгъзаларына карата хөрмәтле һәм кайгыртучан мөнәсәбәттә булу;

9) дөнья һәм Русия халыкларының әдәби мирасын үзләштерү процессында эстетик зәвыкны үстерү.

“Туган тел” фәнен өйрәнү барышында ирешелергә тиеш *метапредмет* нәтиҗәләр булып түбәндәгеләр тора:

1) белем алу максатын һәм бурычларын үзаллы билгеләү, танып белү мотивларын һәм кызыксынучанлыкны үстерү;

2) максатларга ирешү юлларын, уку һәм танып белү бурычларын хәл итүнең эффектив ысулларын аңлы рәвештә сайлау;

3) планлаштырылган нәтиҗәләр белән үз гамәлләреңне тәңгәлләштерә белү, нәтиҗәләргә ирешү процессында эшчәнлекне контрольдә тоту, тәкъдим ителгән шартларда һәм куелган таләпләрдә гамәлләр ысулын билгеләү, үзгәреп торган ситуацияләрдә гамәлләргә коррекция кертү;

4) бәяләү, үзбәяләү нигезләренә ия булу;

5) төшенчәләрне билгели, гомумиләштерә, аналогияләр таба, төркемнәргә бүлә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен күрсәтә, логик фикерләр төзи, нәтиҗә ясый (индуктив, дедуктив, аналогия буенча) алу;

6) модель һәм схемалар, билге һәм символларны төзү, үзгәртү һәм куллана белү;

7) аңлап-төшенеп уку алымына ия булу;

8) яшьтәшләр һәм укытучылар белән уку эшчәнлеген оештыра, төркемдә һәм үзаллы эшли, үз фикереңне формалаштыра, аргументлаштыра һәм аны яклый белү.

“Туган тел” фәнен өйрәнү барышында түбәндәге *предмет* нәтиҗәләре чагылдырылырга тиеш:

1) Формаль һәм формаль булмаган мәдәниятара һәм шәхесара аралашуларда кешеләр арасындагы багланышларның эффектлыгын тәэмин итүче сөйләм эшчәнлеге төрләрен камилләштерү (тыңлап аңлау, уку, сөйләү һәм язу);

2) белем бирү һәм үзаллы белем алу процессында шәхеснең иҗади һәм интелектуаль сәләтләрен үстерүдә телнең мөһим роль башкаруын аңлау;

3) туган телнең коммуникатив-эстетик мөмкинлекләрен куллану;

4) туган тел турындагы фәнни белемне системалаштыру һәм киңәйтү, аның берәмлекләре һәм баскычлары арасындагы бәйләнешләр барлыгына төшенү, туган телнең төп берәмлекләрен һәм категорияләрен, лингвистиканың төп төшенчәләрен үзләштерү;

5) сүзгә төрле төрдәге анализ (фонетик, морфемик, сүзьясалыш, лексик, морфологик), сүзтезмәгә һәм җөмләгә синтаксик анализ һәм шулай ук текстка күпаспектлы анализ ясау күнекмәләрен формалаштыру;

6) актив һәм потенциаль сүзлек запасын баету, аралашу стиленә һәм ситуациясенә ярашлы туган телдә хисләрне һәм уйларны иркен белдерү өчен сөйләмдә кулланылучы грамматик чараларның күләмен киңәйтү;

7) туган тел лексикасының һәм фразеологиясенең төп стилистик ресурсларын, төп нормаларын (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик, пунктацион), сөйләм этикеты нормаларын үзләштерү; аларны телдән һәм язма фикерләрне барлыкка китергәндә сөйләм практикасында куллану тәҗрибәсен булдыру; сөйләмне үзаллы камилләштерүгә омтылу;

8) Гомумкешелек кыйммәте буларак тел мәдәнияте өчен җаваплылык хисе формалаштыру.

**Уку предметының эчтәлеге** бүлегендә үтеләсе темаларның исемлеге һәм аларның кыскача эчтәлеге бирелә.

## Тематик планлаштыру

Тематик планлаштыру эш программасының иң мөһим компоненты булып исәпләнә, чөнки ул уку материалын, уку планына һәм белем бирү оешмасының еллык график эшенә яраклы рәвештә төзелә. Анда дәресләрнең темалары, сәгатьләр саны, планлаштырылган нәтиҗәләр, өй эше, дәресне үткәрү вакыты, искәрмәләр урнаштырыла. Уку материалы тематик план буенча эзмә-эзлекле тормышка ашырыла.

Сезнең карамакка тематик планлаштыруның якынча формасы (берничә вариантта) тәкъдим ителә. (Укытучы аңа мәктәп дәрәҗәсендә сайланылган я методик берләшмә утырышында кабул ителгән формага ярашлы үзгәрешләр кертә ала).

**1 нче вариант**

| Бүлек атама, дәрес темасы | Сәгать саны | Планлаштырылган нәтиҗәләр | | | Өй эше | Үткәрү вакыты | | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Предмет | Метапредмет | Шәхси | | План. | Факт. | |
| | | | | | | | | |

**2 нче вариант**

| Бүлек атамасы, дәрес темасы | Сәгать саны | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Өй эше | Үткәрү вакыты | | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | План. | Факт. | |
| | | | | | | | |

Искәрмәләрдә укытучы үзенә кирәкле мәгълүматны урнаштыра ала.

## Федераль дәүләт белем бирү стандартлары буенча дәрес проектлау нечкәлекләре

Федераль дәүләт белем стандартлары (ФДББС) таләбе укытучыга татар теле дәресләрен оештыруда комплекслы караш булдырырга ярдәм итә, ижади эзләнүләргә юл ача, укучыны шәхес буларак үстерергә, укытуны тормышка якынайтырга булыша.

Традицион укыту системасыннан аермалы рәвештә, хәзерге заман дәресләренең төп үзенчәлекләре түбәндәгеләр.

***Төп максат*** – укучы шәхесенең интеллектуаль, рухи, физик үсеше, аның кызыксынуын формалаштыру;

***Дәрес эчтәлеге*** – теманың тормыш белән бәйлелеге, дөньяны танып белүгә әһәмиятле булуы.

***Белем бирүгә этәргеч көчләр*** – ижат итү, үз үсешеңне күрү, белемне арттырырга омтылу, үз-үзеңә ышаныч, гамь уянуы.

***Эш ысуллары***– бергәләп эзләнү, төркемләп эшләү, эвристик әңгәмә, дәрес-диспут, укытучы һәм укучы арасында эшлекле мөнәсәбәт.

***Дәресне оештыру*:** сорауларга җавап эзләү, тормыш белән бәйле иҗади күнегүләр эшләү, шәхси, төркемле, парлы эш оештыру.

***Укытучы*** – ярдәмче, дус, киңәшче, юнәлеш бирүче. Аның төп бурычы – укучыларны уку мәсьәләләрен хәл итү процессына дөрес җәлеп итү, кызыксындыра белү.

***Төп нәтиҗә*** – укучының белемен яңа ситуациядә мөстәкыйль куллануы, хаталарын күрүе, үз-үзен бәяли белүе.

Традицион рәвештә укыту процессының түбәндәге этапларын билгелиләр (Анри Файол):

• планлаштыру;

• оештыру;

• гамәлгә ашыру;

• коррекция;

• анализ.

Уку-укыту процессының төп формасы буларак, бүген дә дәрес шушы ук принципларга нигезләнә. Укытучы моңа кадәр дә, бүген дә дәресен

алдан планлаштырырга, аны оештыруны ныклап уйларга, алып барырга, укучыларның эшчәнлеген бәяләргә, кирәк булганда төзәтмәләр кертергә, анализ ясарга, контроль-бәяләү эшләрен үткәрергә бурычлы. Белем бирү процессында киң таралган катнаш дәрес мисалында укытучы белән укучы эшчәнлегенә таләпләрне түбәндәгечә билгеләргә мөмкин:

| **Дәрес этаплары** | **Традицион дәрес** | **Заманча дәрес** |
|---|---|---|
| Дәрес темасын игълан итү | Укытучы укучыларга хәбәр итә (җиткерә) | Укучылар үзләре фор малаштыра |
| Максатны һәм бурыч ларны хәбәр итү | Укытучы формалашты ра һәм укучыларга нәр сәгә өйрәнергә тиеш булуларын хәбәр итә (җиткерә) | Белгәннәренең һәм бел мәгәннәренең чиген бил геләп, укучылар үзләре формалаштыра |
| Планлаштыру | Максатка ирешү өчен, укытучы укучыларга нинди эшләр башкарыр га тиеш икәнлекләрен хәбәр итә | Укучылар тарафыннан куелган максатларга ирешү юллары билге ләнә |
| Укучыларның практик эшчәнлеге | Укытучы җитәкчелеген дә укучылар практик эшләр башкара (гадәттә фронталь ысул белән) | Укучылар үзләре билге ләгән планга ярашлы белем алу эшчәнлеген тормышка ашыра (инди видуаль һәм төркемдә) |
| Контрольне тормышка ашыру | Укытучы укучыларның практик эшләр башкару ын контрольдә тота. | Укучылар контрольне үзләре тормышка ашыра (үзконтроль, үзара кон троль формалары кулла ныла) |
| Коррекцияне тормыш | Укытучы укучыларның | Укучылар килеп туган |

| | | |
|---|---|---|
| ка ашыру | эшләрне башкару бары шында һәм нәтиҗәләре буенча коррекцион эш ләр башкара | авырлыкларны үзләре хәл итәргә тырыша |
| Бәяләү | Укытучы укучыларның дәрестәге эшләрен бәяли | Укучылар, нәтиҗәсен нән чыгып, эшчәнлеккә бәя бирәләр |
| Йомгаклау | Укытучы укучыларның нәрсәне истә калдыру ларын ачыклый | Рефлексия үткәрелә |
| Өйгә эш | Укытучы игълан итә һәм аңлата (гадәттә ба рысына да бер үк эш) | Укучылар, үз мөмкин лекләреннән чыгып, тәкъдим ителгән эш төрен сайлап ала |

Китерелгән ике дәрес тибыннан күренүенчә, алар, беренче чиратта, укытучының һәм укучының дәрестәге эшчәнлеге буенча бер-берсеннән аерыла. Традицион типтагы дәрестәге укытучы кушканны гына үтәп утыручыдан укучы хәзер инде төп эшчән кешегә, иҗатчыга әверелә.

Хәзерге заман дәресенә әзерлек вакытында укытучы һәр этапта эш формаларын, методларын, уку материалының эчтәлеген, укучыларның эшчәнлеген оештыру ысулларын сайлаганда, тәнкыйть күзлегеннән карап, укучы белән укытучы тиң хезмәттәшлек итәргә тиеш булудан, җимешле иҗат итү мөмкинлекләрен тудыру кирәклегеннән чыгып эш итәргә, ягъни үзенең һәм укучыларының эшчәнлеген алдан билгеләп, педагогик хезмәттәшлек эчтәлеген планлаштырырга бурычлы. Биредә укучының эшчәнлеге өч яклап та исәпкә алынырга һәм танып белү, коммуникатив һәм регулятив нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлтелгән булырга тиеш.

Уңышлы һәм нәтиҗәле дәрес структурасын түбәндәге шартлар тәэмин итә:

• белем бирүче, тәрбия һәм үсеш максатларын комплекслы планлаштыру;

• дәрес эчтәлегендә һәм темада төп, мөһим материалны аеру;

• дәрес этапларының максатка ярашлы эзмә-эзлеклелеген билгеләү, материалны үзләштерүнең, эшчәнлек төрләренең рациональ бүленешен тәэмин итү;

• иң кулай, эффектив методларны, алымнарны һәм укыту чараларын сайлау;

• укучыларның психо-физиологик, индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алу;

• дәреснең уңай үтүе өчен мораль-психологик шартлар тудыру.

Уку-укыту процессында күпчелек дәресләр катнаш типта (комбинированный) оештырыла. Бу очракта дәреснең күп вакыты (20–30 минут) яңа материалны үзләштерүгә бүленергә тиеш. Яңа материал ныклы үзләштерелсен өчен, аны үтелгән темаларга бәйләп актуальләштерү мөһим. Шуңа күрә яңа тип дәресләрнең башлангыч өлешендә үк белемнәрне актуальләштерү, аның үткән темалар белән бәйләнешен ачыклау, бу яңа белемнәрнең киләчәктә безгә нигә, кайда, кайчан кирәк булачагын билгеләү һәм бик мөһим этаплардан санала. Бу, үз чиратында, предметка һәм темага кызыксынуны арттыра, мөһимлеген, кирәклеген аңларга булышлык итә (мотивацияне күтәрә). Укытучы белән укучыларның хезмәттәшлеге нигезендә туган эшчәнлектә яңа белемнәр үзләштерелә, практик эш төрләрендә ныгытыла. Контроль бу очракта бәяләү ысулы булудан бигрәк ике яклы “укытучы-укучы” бәйләнешенә әйләнә. Йомгаклау рефлексия формасында оештырыла. Бу иң киң таралган катнаш типтагы дәреснең оптималь системасын тәшкил итә.

Дәреснең үзенчәлеге һәм сыйфаты аның максатларына, эчтәлегенә, үткәрү методикасына, укытучыларның һәм укучыларның үзенчәлекләренә бәйләнгән. Укытучылар тарафыннан үткәрелгән күп төрле дәресләрнең гомуми билгеләрен күрсәтү өчен аларны классификацияләргә кирәк. Яңа

буын Федераль дәүләт белем бирү стандартларына ярашлы, нинди максатка юнәлдерелгәнлегенә һәм нинди нәтиҗәләргә килү теләгенә карап, дәресләр түбәндәге типларга бүленә:

| **Дәрес тибы** | **Максат** | **Укытуның нәтиҗәсе** |
|---|---|---|
| Яңа белемне беренче тапкыр күрсәтү дәресе | Предмет буенча яңа белемне беренче тапкыр үзләштерү | Үз сүзләре белән кагый дә, төшенчә, алгоритм нарны барлыкка китерү, үрнәк, алгоритм буенча гамәлләрне эшләү |
| Предмет буенча белем не куллану дәресе | Катлаулы күнегүләрне эшләү өчен предмет буенча белемне куллану | Аерым укучылар яки класс коллективы тара фыннан катлаулы күне гүләр эшләү |
| Йомгаклау һәм система лаштыру (алган белемне системага салу) дәресе | Предмет буенча белем, универсаль эшчәнлекне системалаштыру | Нәтиҗәләр буенча йом гак ясый белү, универ саль уку эшчәнлегенең дәрәҗәсен күтәрү |
| Кабатлау дәресе | Предмет буенча белем не ныгыту. Универсаль уку эшчәнлеген форма лаштыру | Аерым укучылар яки класс коллективы тара фыннан күнегүләрне ха тасыз эшләү; телдән җа вап бирү; үз хатаңны та бу һәм төзәтү; бер-бере нә ярдәм итү |
| Контроль дәрес (тикше рү дәресе) | Практик эшләрне баш каруда предмет буенча белемне тикшерү | Контроль яки үзаллы эшнең нәтиҗәләре |
| Коррекцион (төзәтү) | Хаталар өстендә инди | Үз хаталарыңны табу |

| | | |
|---|---|---|
| дәрес | видуаль эш | һәм төзәтү |
| Катнаш дәрес | Бер дәрес рамкаларында эшли алмаган күнегү ләрне эшләү | Куелган дидактик бу рычларны хәл итү |
| Белем алу экскурсиясе | Тирә-як мохитне, күре нешләрне якыннан өй рәнү | Реаль тормыш ситуа циясендә тирә-як мохит не, күренешләрне якын нан өйрәнгәндә предмет буенча белемгә ия булу һәм аларны куллану; иҗади отчет төзү |
| Проектлар эшләү һәм практика дәресе | Теоретик кагыйдәләрне (положениеләрне) өйрә нүне практик якка юнәлтү | |

Дәресләрнең типологиясе белән рәттән хәзерге методика фәне дәреснең структурасына да зур игътибар юнәлтә. Дәреснең структурасы – аның бөтенлеген тәэмин итүче барлык элементларының берләшмәсе. Дәреснең өлешләре бер-берсе белән тыгыз бәйләнә һәм билгеле тәртиптә эзмә-эзлекле рәвештә төзелә. Дәреснең структурасы куелган максатларга, үзләштереләчәк материалның эчтәлегенә, укыту методлары һәм алымнарына, укучыларның белем һәм үсеш дәрәҗәсенә, укыту процессында дәреснең урынына бәйле. Дәреснең төп дидактик структурасы (төзелеше) дәреснең план-конспектында һәм технологик картасында чагылыш таба.

**Яңа тема өйрәтү дәресенең якынча структурасы**

1) Тема, максат, бурычлар билгеләү. Ике тема бирү үзен аклаячак: теоретик материал өйрәнү буенча һәм тәрбияви, үстерүче максатлардан чыгып, лексик тема алына. Мәсәлән: *Сыйфат дәрәҗәләре. Кешедә барысы да матур булырга тиеш.*

2) Оештыру моменты (эшчәнлеккә әзерлек).

Максаты: укучыларны төп эшчәнлеккә җәлеп итү. Сыйныфта уңай эмоциональ атмосфера булдыру.

Эш алымнары: укытучының изге теләкләре, бүгенге эш өчен кирәкле сыйфатларны билгеләү, девиз, эпиграф белән таныштыру, өлге буенча өй эшен мөстәкыйль тикшерү һ.б. (1, 2 минут).

3) Белемне актуальләштерү.

Максат: бүгенге темага нигез булырлык итеп, үтелгәнне кабатлау, уку- чыларга авыр тоелган урыннарны ачыклау (4, 5 минут).

4) Проблемалы ситуация булдыру. Уку мәсьәләсен кую.

Максат: авырлыкларны ачыклау (Ни өчен шундый сорау килеп туды? Без әле нәрсәне белмибез?), дәрес максатын я теманы төп сорау кебек итеп билгеләү (4, 5 минут).

Уку мәсьәләсен кую буенча проблеманы ачыклауга юнәлтелгән, темага алып килгән әңгәмә үткәрү.

5) Яңа тема өйрәнү.

Максат: мәсьәләне телдән чишү юлларын бергәләп эзләү, анализлау (7, 8 минут).

Эш төрләре: төрле фикерләр тудырган, проблеманы хәл итүгә юнәлтелгән әңгәмә, төркемләп, парлап эшләү.

6) Ныгыту.

Максат: бергәләп, чиратлап яңа белемне кабатлау, терәк сигнал формасында теркәү (4, 5 минут).

Эш төрләре: фронталь эш, парлы эш, продуктив күнегүләр башкару.

7) Үз аллы эш.

Максат: һәр укучыны теманы аңлавына, күнегүләр башкара алуына ышандыру (4, 5 минут).

Эш төрләре: 2, 3 зур булмаган язма эш башкару, укучыларның өлге буенча үзләрен тикшереп барлавы.

Яңы теманы кабатлау, ныгыту.

Укучыларга яңа тема буенча эш тәкдим ителә (1 күнегеү), алга таба шушы ук күнегү алдан үтелгән темалар белән бәйләп ныгытыла (7, 8 минут).

8) Рефлексия (дәрес нәтиҗәсе).

Максат: укучыларның үз уку эшчәнлеген, сәләтләрен дөрес бәяләү, башкаларның эшчәнлеген күрә һәм дөрес анализлый белүе (2, 3 минут).

Сораулар: Нинди максатлар куйган идек? Максатларга ирештекме? Ничек? Нәтиҗәләр нинди? Тагы да нәрсәләр эшләргә тиешсез? Бүгенге белемне тормышта кайда һәм ничек кулланырга мөмкин? Синең бигрәк тә кайсы эшең уңышлы килеп чыкты? Алга таба нәрсә өстендә эшләргә кирәк?

**Белем һәм күнекмәләрне комплекслы куллану дәресенең якынча структурасы (ныгыту дәресе)**

1) Оештыру этабы.

2) Өй эше тикшерү. Укучыларның тирәк белемнәрен яңадан барлау һәм төзәтмәләр кертү. Белемнәрне актуальләштерү.

3) Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

4) Беренчел ныгыту:

– таныш ситуациядә (типлаштырылган);

– үзгәртелгән ситуациядә (конструктив).

5) Белемнәрне яңа ситуациядә иҗади куллану һәм эзләп табу (проблемалы биремнәр).

6) Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү.

7) Рефлексия (дәрескә йомгак ясау).

## Белем һәм күнекмәләрне актуальләштерү дәресенең якынча структурасы (кабатлау дәресе)

1) Оештыру этабы.

2) Өй эше тикшерү. Куелган бурычларны иҗади чишү өчен кирәкле белем һәм күнекмәләрне яңадан барлау һәм төзәтмәләр кертү.

3) Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

4) Белемнәрне актуальләштерү:

– контроль дәрескә әзерлек максатыннан;

– яңа теманы өйрәнүгә әзерлек максатыннан.

5) Белем һәм осталыкларны яңа ситуациядә куллану.

6) Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру. Үзләштерү дәрәҗәсен ачыклау. Җибәрелгән хаталар буенча фикер алышу һәм төзәтмәләр кертү.

7) Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү.

8) Рефлексия (дәрескә йомгак ясау).

## Белем һәм осталыкларны системалаштыру дәресенең якынча структурасы

1. Оештыру этабы.

2. Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

3. Белемнәрне актуальләштерү.

4. Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру.

Укучыларны гомумиләштерелгән эшчәнлеккә әзерләү. Тиешле дәрәҗәдә яңадан үзләштерү (үзгәртелгән сораулар белән).

5. Белем һәм осталыкларны яңа ситуациядә куллану.

6. Үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, җибәрелгән хаталар буенча фикерләшү һәм аларны төзәтү.

7. Рефлексия (дәрескә нәтиҗә ясау). Эшчәнлеккә нәтиҗә ясау, өйрәнелгән материалны анализлау.

**Белем һәм осталыкларны контрольләштерү**
**дәресенең якынча структурасы**

1) Оештыру этабы.

2) Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

3) Белем, осталык һәм күнекмәләрне тикшерү (биремнәр күләме һәм авырлык дәрәҗәсе буенча программага һәм һәр укучының белем дәрәҗәсенә туры килергә тиеш).

Контроль дәресләрнең формалары:

– язма контроль;

– телдән һәм язма контроль аралаштырып бирелгән булырга мөмкин.

4) Рефлексия (дәрескә нәтиҗә ясау).

**Белем, осталык һәм күнекмәләргә төзәтмәләр**
**кертү дәресенең якынча структурасы**

1) Оештыру этабы.

2) Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

3) Белем, осталык һәм күнекмәләрне диагностикалауның нәтиҗәләре. Укучыларның белем һәм күнекмәләрендәге хаталарны ачыклау, аларны төзәтү юлларын, белем һәм осталыкларын камилләштерү. Диагностика нәтиҗәләре буенча укытучы коллектив, төркемнәрдә һәм индивидуаль эшләү алымнарын планлаштыра.

4) Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү.

5) Рефлексия (дәрескә йомгак ясау).

**Катнаш дәреснең якынча стуктурасы**

1) Оештыру этабы.

2) Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

3) Белемнәрне актуальләштерү.

4) Яңа белемнәрне беренчел үзләштерү.

5) Яңа белемнәрне үзләштерүне беренчел тикшерү.

6) Беренчел ныгыту.

7) Үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, җибәрелгән хаталар буенча фикер алышу һәм төзәтүләр кертү.

8) Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча аңлатма бирү.

9) Рефлексия (дәрескә йомгак ясау).

## Дәреснең технологик картасы

“Технологик карта” төшенчәсе педагогика фәненә төгәл, техника җитештерү өлкәләреннән килеп керә. Технологик карта – җитештерелгән эшләнмәнең эшкәртелү процессын, составын, чималын, технологик режимын, коралларын, җитештерелү вакытын, җитештерүченең квалификациясен һ.б. тасвирлаган технологик документациянең бер формасы. Дәреснең технологик картасы – укытучы һәм укучы арасындагы үзара педагогик эшчәнлекне планлаштыра торган заманча бер форма. Шул рәвешле, дәреснең технологик картасы – дәреснең гомумиләштерелгән, график тасвирламалар ярдәмендә башкарылган сценариясе, дәресне проектлаштыруның нигезе, укытучының шәхси эш методлары белән таныштыру чарасы.

Технологик карта ярдәмендә белем бирү укыту-тәрбия процессын нәтиҗәле итеп оештырырга, ФДББС таләпләре нигезендә предмет, метапредмет һәм шәхси осталыкларының үсешен тәэмин итәргә, укытучының дәрескә әзерләнү вакытын җитди дәрәҗәдә киметергә ярдәм итә.

Технологик картаны кулланып башкарылган проектлы педагогик эшчәнлекнең асылы – мәгълүмат белән эш иткәндә инновацион технологияләрне куллану, теманы үзләштерү өчен бирелгән биремнәрнең

тасвирламасын бирү, көтелгән нәтиҗәләрне формалаштыру. Технологик картаның үзенчәлекләреннән интерактивлыкны, алгоритмлыкны, төзеклелекне, мәгълүматларның гомумиләшүен билгеләргә була.

Технологик карта укытучыга түбәндәге мөмкинлекләрне бирә:

– ФДББС нигезендәге планлаштырылган нәтиҗәләрне тормышка ашыру;

– конкрет теманы өйрәнү процессында формалашачак УУГ билгеләү;

– укучыларда эзлекле рәвештә УУГ формалаштыру;

– дәрес темасын үзләштерүне күздә тотып, максаттан алып ахыргы нәтиҗәләренә кадәр булган эшчәнлекнең эзлеклелеген проектлаштыру;

– билгеле дәрес этабында каралган төшенчәләргә төшенү дәрәҗәсен билгеләү;

– эшчәнлекне чиреккә, яртыеллыка, уку елына проектлаштыру;

– иҗади эшчәнлеккә вакыт булдыру;

– предметара белемнәрнең тормышка ашу мөмкинлекләрен билгеләү;

– предметара бәйләнешне тудыру;

– укыту-тәрбия процессында катнашучыларның килешенгән гамәлләрен оештыру;

– планлаштырылган нәтиҗәләрнең гамәлдә ни дәрәҗәдә ирешелгәнлекләрен ачыклау һәм диагностика үткәрү;

– оештыру-методик мәсьәләләрне чишү;

– белем бирүнең сыйфатын арттыру.

Технологик карта мәктәп җитәкчелегенә программаның үтәлешен һәм көтелгән нәтиҗәләрнең ирешү дәрәҗәсен контрольдә тотарга, кирәкле методик ярдәм күрсәтергә ярдәм итә.

| | |
|---|---|
| Укытучы | |
| Дәрес | Татар теле |

| | |
|---|---|
| Сыйныф | |
| Дәрес төре | |
| Дәреснең технологик төзелеше | |
| Дәрес темасы | |
| Максат | |
| Төп терминнар, аңлатмалар | |

| **Ирешеләчәк нәтиҗә** | |
|---|---|
| Предмет нәтиҗәләр | |
| Метапредмет нәтиҗәләр | |
| Шәхси нәтиҗәләр | |
| **Эшне оештыру** | |
| Эш формалары | Ресурслар |
| Фронталь эш, төркемнәрдә һәм парларда эш, индиви дуаль эш | Куллану өчен дәреслек: Хәйдәрова Р.З. Күңелле татар теле. Дәреслеккә методик кулланма. Эш дәфтәре. Тикшерү-бәяләү материаллары. Техник чаралар: компьютер, пре зентация, мультимедиадиск. |

**Өйрәнү технологиясе**

| Дәрес этаплары | Формалаштырылырга тиешле универсаль уку гамәлләре (УУГ) | Слайдлар, күрсәтмәлекләр, картина | Укытучы гамәлләре | Укучылар гамәлләре |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

## Дәрескә үзанализ һәм анализ ясау

Дәресне үткәргәннән соң, аңа җентекле анализ үткәрелергә тиеш. Андый анализ дәреснең уңышлы яки уңышсыз үтүен, кулланылган эш төрләренең һәм методларының эффективлыгын билгеләргә ярдәм итә, укучыларның потенциалын ачыклый, перспективаларны ача һ.б. Һәр дәрестән соң укытучы үзенең дәресенә анализ ясаганда:

• куелган максатларга характеристика бирә һәм аларга ирешү-ирешмәүне анализлый;

• материалның күләме һәм аларны укучыларның үзләштерү сыйфаты турында мәгълүмат бирә;

• укучыларның активлыгын бәяли һәм аларның эшчәнлеген оештыруда кулланылган алымнарның эффектлылыгын билгели;

• үз эшчәнлелегенең аерым аспектларына бәя бирә (сөйләм, логика, укучылар белән мөнәсәбәт булдыру һ.б.);

• йомгаклауда укытучы дәреснең сыйфатын яхшырту буенча үз тәкъдимнәрен әйтә һәм үз педагогик осталыгын камилләштерү буенча чаралар билгели.

Хезмәттәшләре алдында үз дәресенә бәя биргәндә, түбәндәге алгоритмга нигезләнеп, укытучы тарафыннан үзанализ ясала.

## Дәрескә үзанализ схемасы

Класс______ катнашучылар саны________ исемлек буенча _______

Дәреснең темасы ___________________________________________

1. Дәреснең төре һәм структурасы.

2. Бу дәрес үткәне белән ничек бәйләнгән?

3. Дәрескә комплекслы максат нинди (белем бирүче, үстерүче, тәрбияви)? Бу максатларның тормышка ашырылуына бәя бирергә, дәреснең нәтиҗәлелеген нигезләргә.

4. Дәреснең максатына ярашлы эчтәлеген, белем бирү (укыту) формаларын һәм методларын сайлап алуны исбат итәргә. Дәрестә белем бирүнең нәтиҗәләренә нигезләнеп, дәреснең төп этабын билгеләргә һәм аңа тулы анализ ясарга.

5. Дәрес этапларына материаллар һәм эшләр рациональ бүленгән идеме? Этаплар арасындагы бәйләнешләр логик саклanaмы?

6. Дәрес максатына ярашлы дидактик материалларның, техник укыту чараларының, күргәзмә әсбапларның, таратма материалларның сайлап алынуын нигезләргә.

7. Укучыларның белемнәрне үзләштерүен тикшерү ничек оештырылды? Дәреснең кайсы этабында? Нинди формаларда һәм нинди методлар ярдәмендә тормышка ашырылды?

8. Дәрестәге психологик атмосфера.

9. Дәрес нәтиҗәләрен ничек бәялисез? Куелган бурычлар тормышка ашырылдымы? Әгәр үтәлмәсә, ни өчен?

10. Үз эшчәнлегенең перспективаларын билгеләргә.

## ФДББС таләпләре буенча дәрескә анализ ясау схемасы

Яңача төзелгән һәм оештырылган дәрескә анализ ясаганда түбәндәгеләр исәпкә алына.

1. Дәрескә укытучы тарафыннан куелган белем бирүче, үстерүче һәм тәрбияви максатларның тормышка ашырылуы күзәтеләме?

2. Дәреснең төре, структурасы, этаплары һәм аларның эзмә-эзлеклелеге, вакыт буенча бүленеше дәреснең максатларына, эчтәлегенә ярашлымы?

3. Дәреснең ФДББС таләпләренә туры килүе.

3.1. Дәреснең яңа белемнәр алу (үзләштерү) нәтиҗәләренә юнәлтелгән булуы.

3.2. Дәрес барышындагы эшчәнлекнең укучыларның универсаль уку эшчәнлеген формалаштыру максатында оештырылуы.

3.3. Белем бирү процессында заманча технологияләрнең кулланылуы (проект, тикшеренү, ИКТ һ.б.).

4. Дәреснең эчтәлеге.

4.1. Дәрес материалының укучыларның яшь үзенчәлекләренә карап сайлап алынуы. Аның балаларның психо-физиологик мөмкинлекләренә туры килүе.

4.2. Дәрес эчтәлегенең программа таләпләренә туры килүе.

4.3. Теориянең практика белән бәйләнеше, укучыларның тормыш тәҗрибәсен, аларның танып белү активлыгын һәм үзаллылыгын үстерү максатында файдалану.

4.4. Үзләштерелүче материалның үтелгәннәре белән бәйләнеше, предметара бәйләнешләр.

5. Дәресне үткәрү методикасы.

5.1. Укучыларның белемнәрен һәм эшчәнлек алымнарын актуальләштерү. Укытучы тарафыннан проблемалы сораулар куелуы, проблемалы ситуацияләр тудырылуы.

5.2. Укытучы нинди методлар кулланды? Репродуктив һәм эзләнү (тикшеренү) эшчәнлек төрләре күпме өлеш тәшкил итә? Чагыштыр: “укы”, “сөйлә”, “кабатла”, “исеңә төшер” – репродуктив характерда, “исбат ит”, “аңлат”, “бәялә”, “чагыштыр”, “хатасын тап” – эзләнү (продуктив) характерда.

5.3. Укытучы эшчәнлеге белән укучы эшчәнлегенең нисбәте. Үзаллы эшләрнең күләме һәм характеры.

5.4. Укытучы түбәндә санап үтелгән нинди танып белү методларын куллана (күзәтү, тәҗрибә, мәгълүмат эзләү, чагыштыру, уку)?

5.5. Аралашуда диалог формалары кулланамы?

5.6. Укучыларның белемен файдаланганда стандарт булмаган ситуацияләр тудырылуы.

5.7. Кире бәйләнеш булдырылуы.

5.8. Фронталь, төркемләп, парлап һәм индивидуаль эшләү кебек эш төрләрен аралаштыру.

5.9. Дифференциаль укытуны тормышка ашыру. Төрле хәзерлекле укучыларга аерым эш төрләре, биремнәр булуы.

5.10. Белем бирү чаралары. Темага һәм дәрес этабына ярашлы аларның максатлы файдалануы.

5.11. Күргәзмә материалларны файдалану: күргәзмә материал сыйфатында, эмоциональ мохит тудыру өчен, укыту (белем бирү, белем алу), мәсьәләләрен хәл итү өчен (җитәрлек, артык күп, урынлы, җитәрлек дәрәҗәдә түгел).

6. Дәреснең психологик нигезләре.

6.1. Укытучы тарафыннан укучыларның яшь үзенчәлекләре, мөмкинлекләре, кызыксынулары исәпкә алынуы.

6.2. Белем бирүнең үстерүче (развивающая) функциясенең тормышка ашырылуы. Кабул итү, игътибар, күз алдына китерү, фикерләү, хәтер, сөйләм сыйфатларын үстерү.

6.3. Дәреснең ритмы: төрле дәрәҗәдә авырлыктагы материалның чиратлашып килүе, уку эшчәнлегенең төрлелеге.

6.4. Психологик паузаларның, көчергәнешне чишү алымнарының булуы. Дәреснең эмоциональ атмосферасы.

7. Өйгә эш: күләме, аңлаешлы инструктаж, дифференциация, сайлап алу мөмкинлеге.

8. Укытучының иҗади карашы, педагогик яңалык кертүе.

## Әдәбият


1. 2014/2015 нче уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре: методик тәкъдимнәр. – Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2014. – 52 б.

2. Әминева Р.Ә. Яңа буын стандартларына күчү шартларында рус телле мәктәпләрдә башкорт телен укыту// Башкортостан укытучысы. – 2012. - №11. – Б.16-20.

3. Габитова З.М. Эш программасын эшкәртү буенча методик киңәшләр. Башкорт теле. – Уфа: БР МҮИ нәшр., 2014. – 24 б. (башкорт телендә).

4. Дорожкина Т.Н., Першина Л.Р. Проектирование урока по русскому языку и литературе в свете требований ФГОС: Методические рекомендации. – издание 2-е, испр. и дополн. – Уфа: Издательство ИРО РБ. 2015. – 44 с.

5. Илмөхәммәтов Ә.Г. Хәзерге заман башкорт теле дәресләрен проектлау: Методик киңәшләр. – Уфа: БР МҮИ нәшр.,2015. – 44 б.

6. Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик алымнар. – Алабуга: АИ КФУ нәшрияты, 2012. – 136 б

7. Камаева Р.Б., Мөхәммәтҗанова А.Х. Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм. – Казан: ТР МҮИ , 2015. – 110 б.

8. Татар теле һәм әдәбият укытучысына ярдәмгә: ФДББС турында белешмәлек һәм терәк схемалар: методик ярдәмлек / төзүчеләр: А.Х. Мөхәммәтҗанова, Р.Б. Камаева, – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 68 б.

9. Фәхрисламова Г.И. Дәресне заманча төзү методикасы хакында // Башкортостан укытучысы. – 2012. -№12. – Б.13-18.

10. https://education.bashkortostan.ru/presscenter/news/581404/